**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«22» декабрь 2021 ел                                                                                    № 3

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы  131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы  45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 22 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән,  балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Иске Урыссу торак пунктындагы Октябрь, 1 Май урамнарындагы юлларны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, төзелеш материаллары сатып алу, кайтару, түшәү, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Иске Урыссу торак пунктында хәтер скверы төзү (проект төзү, проект төзү буенча хезмәткә түләү, төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу, скверның нигезен төзү, мемориал сатып алу һәм аны урнаштыру, килешү нигезендә эш өчен түләү);
- зиратның коймасын алмаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү)”.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 572 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 290 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда 276 кеше тавыш бирде;
- «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 14 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында  халык җыенын узды дип танырга,  халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Иске Урыссу торак пунктындагы Октябрь, 1 Май урамнарындагы юлларны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, төзелеш материаллары сатып алу, кайтару, түшәү, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Иске Урыссу торак пунктында хәтер скверы төзү (проект төзү, проект төзү буенча хезмәткә түләү, төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу, скверның нигезен төзү, мемориал сатып алу һәм аны урнаштыру, килешү нигезендә эш өчен түләү);

- зиратның коймасын алмаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча түләү);

- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү)" буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова